**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
ЧЕРЕМШАНСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
**СОВЕТ МОРДОВСКО-АФОНКИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**

423103, Мордовское Афонькино село, Цаплина ул., 19 дом

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
ЧИРМЕШӘН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
**МОРДВА АФОНЬКЭСЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

423103, Мордва Афонькәсе авылы, Цаплин урамы 19нчы йорт

тел. (84396) 3-48-29 факс (84396)3-48-49 emai: Mord.Cmn2@tatar.ru

15 декабрь 2025 ел № 09

**Татарстан Республикасы**
**Чирмешән муниципаль районының**
**Мордва Афонькәсе авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

Мордва Афонькәсе авыл җирлеге Башкарма комитетының 2026 елга җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә бюджет ассигнованиеләре бүлеп бирү турындагы мөрәҗәгатен карау хакында

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы, «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 24.5 статьясына һәм «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 77 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 2015 елның 5 октябрендәге 288-ФЗ номерлы Федераль законнар нигезендә, Башкарма комитетның 2025 елның 24 октябрендәге № 136 карарын карап, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Мордва Афонькәсе авыл җирлеге Советы КАРАР КЫЛДЫ:

1. 2026 елга Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Мордва Афонькәсе авыл җирлеге бюджетына бюджет ассигнованиеләренең җитәрлек булмавын исәпкә алып, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Мордва Афонькәсе авыл җирлеге башкарма комитеты мөрәҗәгатендә күрсәтелгән җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә аерым вәкаләтләрне финанслаудан кушымта нигезендә баш тартырга.

Мордва Афонькәсе
авыл җирлеге
башлыгы, Совет рәисе А.И.Митяев

Советның 2025 елның 15 декабрендәге
09 номерлы карарына
1 нче кушымта

2026 елда бюджет ассигнованиеләрен бүлеп бирү өчен җирле әһәмияттәге мәсьәләләр исемлеге

| № п/п | Бюджет ассигнованиеләре белән ныгыту өчен җирле әһәмияттәге мәсьәләләрнең аталышы | Сумма барлыгы, мең сум. |
|---|---|---|
| 1. | Су белән тәэмин итү лицензиясен алу өчен документлар әзерләү | 100 |
| 2. | Мордва Афонькәсе һәм Лагерка авылларында рөхсәтсез чүплекләрне рекультивацияләү | 500 |
| 3. | Шәһәр төзелеше планын әзерләү | 0 |
| 4. | Янгын гидрантларын ремонтлау һәм алыштыру | 100 |
| 5. | Җирле әһәмияттәге юлларны норматив хәлдә тоту өчен махсус реагентлар сатып алу | 200 |
| 6. | Эчә торган суның сыйфатын СанПиНның билгеләнгән таләпләренә туры китерү | 400 |
| 7. | Җир асты чыганакларын санитар саклау зоналары проектын эшләү | 50 |
| 8. | Дератизация чараларын үткәрүне тәэмин итү | 50 |
| 9. | Мордва Афонькәсе, Лагерка авылларында гидротехник корылмаларны декларация алдыннан тикшерү | 500 |
| 10 | Мордва Афонькәсе һәм Лагерка авылларында янгынга каршы чаралар (түбә һәм сәхнә тартмасы пропиткасы) | 70 |
| 11 | Мордва Афонькәсе һәм Лагерка авылларында ашыгыч рәвештә тавыш белән хәбәр итүнең автоном системасын урнаштыру | 20 |
| 12 | Мордва Афонькәсе һәм Лагерка авыллары мәдәният йортларында видеокүзәтү урнаштыру (8 камера) | 100 |
| 13 | Янгын сигнализациясен ремонтлау | 25 |
| 14 | Металлодетекторлар сатып алу | 17 |
|  | Барлыгы: | 2132 |